# СИНЕ УЙЛАП ЯНАМ

*САФЬЯН ИБРАҺИМОВ музыкасы*
*ИЛДАР ЮЗЕЕВ сүзләре*

Җәйләүләрдә тугай,
Тугайларда тургай
Җилләргә лә каршы баралмый.
Сине уйлап янам,
Ник килмисең һаман,
Күңелем эзли сине, табалмый.

Карурманга таба
Чишмә чынлап ага,
Җил көчәйтә аның агышын.
Мин утырам тыңлап,
Шул сулардай чыңлап,
Агып китәр микән сагышым?

Җәйләүләрдә тугай,
Тугайларда тургай
Канатларын җилпи җилләрдә,
Сине уйлап янам,
Ник килмисең һаман.
Күңелләрең синең кемнәрдә?